**СОВЕТ**
**Кулегашского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Күләгәш авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.06.2020 Күләгәш авылы № 55-1

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1.Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Советы депутатларын сайлау көне дип 2020 елның 13 сентябрен билгеләргә.

2.Әлеге карарны “Әгерҗе хәбәрләре” (“Агрызские вести”) район газетасында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы рәсми сайтында agryz.tatarstan.ru кабул ителгән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
авыл җирлеге башлыгы Ю.Н. Васильев